КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 апрель г.Казань № 407

Югары белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыру буенча дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Югары белем бирү мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын;

«Югары белем бирү мәгариф программаларын – специалитет программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын;

«Югары белем бирү мәгариф программаларын – магистратура программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын;

«Аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь, 850 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 11 ноябрь, 850 нче карары белән расланган Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 28 декабрь, 993 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь,

850 нче карары белән расланган Югары белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 8 июнь, 358 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин